Югары Ослан муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә,

№ 44-600

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми, Югары Ослан, Введенский Бистәсе, Вахитов, Куралово, Килди, Карагуҗа, Канаш, Макыл, Мәйдан, Яңа Рус Мәмәтхуҗасы, Октябрьский, Соболевский, Бурнаш, Печищи, Яр буе Морквашы, Түбән Ослан, Шилангы, Ямбулат авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында күрсәтелгән авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары тәкъдимен кабул итәргә:[i]

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына:

Югары Ослан муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның планлы чорына бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы.

4. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин